**Кайбыч муниципаль районы Әбрар Сәгыйди исемендәге Кошман гомуми төп белем мәктәбе укытучысы Хәмидуллина Мәдинә Сәлимхан кызы**

# Тема: Шифалы үләннәр

# * Шифалы үләннәр





* Урманнарда
* Болыннарда
* Тауларда





* ***Исеме сәер булса да***
***Аны бик хөрмәтлиләр:***
***Киселсә дә, канаса да,***
***Иң әйбәт дару диләр.***



* **Бака яфрагы** ягъни русча **подорожник**
* Бу үләндә микробларны үтерүче мәтдә бар. Корт чаккан җирләргә согы бик файдалы. Медицина өлкәсендә яфрагы кулланыла.

* Нечкә яшел сабакта,
* Юл буенда, шар үскән.
* Кай арада җил искән?
* Ак шар очкан да киткән.





* **Тузганакның тамыры бик файдалы. Йокысызлыктан интеккәндә, аппетит булмаганда, ашказаны авыртканда кулланыла. Чәчкәсеннән кышкылыкка варенье ясыйлар.**

* Без таныйбыз дус-ишне,
* Кара, нинди хуш исле!
* Тагып йөрерлек түшкә…
* Бу бит – зәңгәр ……… мәтрүшкә.




* **Мәтрүшкә салкын тигәннән кулланыла. Чәчәге дә, яфрагы да бик файдалы.**



* **Мәтрүшкәнең** була тагын сарысы.

* **Алтмыш төрле авыруга: Эчәк, тамак, бавырларга, Нервларга дәва - шул.**

* Ә менә монысы үги – ана яфрагы.



Үги – ананың яфрагы кулланыла. Ул ютәлдән бик файдалы.



**Исеменә туры килә җисеме дә –**
**Аскы ягы ефәк кебек, ә өскесе –**
**салкын кар кебек.**

* Сары төсе – бал кебек,
* Ак чуклары – кар кебек
* Әллә ничә авыруга
* Файдасы бар, эч белеп



* Ромашка авыртуны баса, ютәлдән бик файдалы, тамак авыртканда, тамакны да чайкасаң, бик файдасы тия. Аның чәчкәләре кулланыла.

* *“Агулы үсемлекләр”*

* Волчий ягоды



* **Бу үсемлек – Бүре җиләге. Җимешләре кызыл төстә, кызыктырып тора. Бик агулы.**

* Белена-Тилебәрән орлыгы



* **Бу үсемлек – Тилебәрән орлыгы. Аның орлыклары мәк орлыгына охшаган. Кешене тилертә.**

* Бу үсемлек – Карга күзе. Дүрт яфрак һәм уртасында кара бер җимеш. Ашарга ярамый, агулы.

* Борщевик-Балтырган






* **Бу үсемлек – Балтырган. Аның суы кешенең тәненә тисә, пешерә. Димәк балалар, үсемлекләрне яхшы белмичә, теләсә кайсын җыярга ярамый**

*Үсемлекләрнең яфраклары, чәчкәләре, тамыры гына түгел, җимешләре дә файдалы икән. Нинди үсемлекләр икән алар?



* **Бу – миләш. Ул баш авыртканда кулланыла.**

Бу – балан. Ул ашказаны авыртканда, кан туктату өчен дә кулланыла.



* Бу – кура җиләге. Ул салкын тигәннән бик файдалы. Температураны төшерү чарасы.







* **Бу- гөлҗимеш. Ул хәл булмаганда, витамин буларак кулланыла.**

* Кара карлыган. Ул хәтер начар булганда, тын юлларына салкын тигәндә бик файдалы.





* **Кызыл карлыган**







**Укучылар! Табигатьне саклыйк һәм аннан дөрес файдаланыйк**